| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 сентябрь 2019 ел Шалты авылы № 9

**Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә 18 яшькә җиткән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге территориясендә 2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 250 (ике йөз илле) сум үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында җирле референдумга чыгарыла торган сорауны тәкъдим итәргә.

- Шалты авылы урамнарын кардан һәм чүп үләннәреннән чистарту
- Шалты авылында Совет, Новая һәм Мира урамнары буенча чокырлар ремонты

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авыл җирлеге Советына җибәрергә.

Җитәкче З.Х. Фаткуллин